СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР

26.08.2024 | с. Верхний Услон | № 50-657

# Муниципаль хезмәт вазыйфаларын кыскарту турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшен камиллəштерү максатларында, «Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге 1721 номерлы карары белән,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мәдәният бүлеге» МКУ баш белгече» муниципаль хезмәт вазыйфасының штат берәмлеген 2024 елның 26 августыннан кыскартырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетына «Югары Ослан муниципаль районының мәдәният бүлеге» МКУның штат расписаниесенә тиешле үзгәрешләр кертергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгына җибәрергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В. Осянин